# КЕРЕШ

Соңгы елларда илдәге иҗтимагый-икътисади вазгыять милли телләргә карата игътибарны көчәйтергә мәҗбүр итте. Аеруча узган гасыр ахырында кабул ителгән «Россия Федерациясе халыклары телләре турында»гы (1991), «Белем бирү турында»гы законнар (1992, 2012) республикаларның милли телләренә дәүләт теле статусын бирү турындагы нигезләмәне актуальләштерделәр, белем бирү концепциясен булдыру проблемасын алгы планга чыгардылар. Бу документлар телне аралашуның мөһим коралы һәм чарасы итеп кенә түгел, бәлки шәхеснең милли үзаңын чагылдыручы мәдәниятнең мөһим бер өлеше икәнлеген дә дәлиллиләр. Шуңа күрә дә «Татарстан Республикасы халыклары телләре турында»гы Закон (1992), «Татарстан Республикасы халыклары телләрен саклау, өйрәнү һәм үстерү буенча Татарстан Республикасы дәүләт программасы» (1994), «Татарстан Республикасы дәүләт телләре һәм Татарстан Республикасында башка телләр турында Татарстан Республикасы Законы» (2004), «2004—2013 елларга Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү буенча Татарстан Республикасы дәүләт программасы» (2004), «Татарстан Республикасында дәүләт теле буларак татар телен куллану турында»гы Закон (2013) һәм башка норматив-хокукый документлар республиканың дәүләт телләре һәм башка телләрнең җәмгыятьтәге статусын билгеләделәр, аларның кулланылыш даирәсен киңәйттеләр. Шул рәвешчә, Россиядә халык саны буенча икенче урында торган татар телен барлык милләт вәкилләренә укытуның бөтен бер системасын эшләү өчен, хокукый нигез булдырылды. Урта (тулы) гомуми белем бирү оешмаларында татар теленең туган тел һәм чит тел буларак әһәмиятен һәм урынын билгели торган объектив шартлар әлеге проблемага яңача концептуаль якын килү өчен җирлек тудырды.

Хәзерге вакытта милли мәгариф системасы яңа таләпләр нигезендә укытуның сыйфатын һәм нәтиҗәлелеген күтәрү юнәлешендә алга бара. Ул татар һәм рус телләренең дәүләт статусына ия булуы белән бәйләнгән.

Билгеле булганча, «2014—2020 елларга Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү буенча Татарстан Республикасы дәүләт программасы»н (2013) Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе белән берлектә Казан федераль университеты галимнәре эшләде. Әгәр аңа кадәр кабул ителгән программа буенча республикада икетеллелекне гамәлгә ашыру өчен, 10 елга бары тик 124 млн сум акча тотылган булса, хәзер бу программаны үтәү өчен, республика бюджетыннан 7 елга 1 млрд 84,2 млн сум акча каралган. Димәк, безне алда җитди үзгәрешләр көтә.

Татарстанда телләрне үстерү һәм саклауның төп юнәлешләрен үз эченә алган бу программада куелган бурычларны хәл итү җиде блокка берләштерелгән. Шулар арасында: тел сәясәтен тәэмин итү өчен, норматив-хокукый документлар эшләү (законнарны татарчага тәрҗемә итү, федераль һәм регион законнарын тәңгәлләштерү, хокук мәсьәләләренә караган документлар, методик кулланмалар әзерләү һ. б.); республиканың дәүләт телләре булган татар һәм рус телләренең тигез күләмдә гамәлгә куелышын тәэмин итү (ике тел өлкәсенә караган «ашыгыч лингвистик ярдәм» проекты, тел сертификациясен оештыру, географик атамаларның бердәм каталогын (татар һәм рус телләрендә) төзү, чит илләрдән республикага күчеп килүчеләргә рус телен өйрәнү буенча ярдәм күрсәтү һ. б.); татар һәм рус телләрен өйрәнүнең һәм шул телләрне укытуның тулы бер системасын эшләү (УМКлар, икетеллелек шартларында югары уку йортларында татар телен укыту мәсьәләләре һ. б.); татар һәм рус телләрен саклау, үстерү максатыннан, фәнни һәм фәнни-методик юнәлешне көчәйтү (татар теленең электрон корпусын булдыру, информацион һәм коммуникацион технологияләрнең татар телендә кулланылышын тәэмин итү) һ. б. мөһим бурычлар тора.

Башка телләрдәге кебек үк татар телен чит тел буларак укыту методикасында да яңа юнәлешләр, технологияләр туып тора һәм алар гамәлдә уңышлы гына кулланыла. Рус-татар (бу очракта башка милләт вәкилләрен дә күзаллыйбыз. — *Ф. Х.*) икетеллелеге башка төрле нигезгә — аралашу (коммуникатив) нигезенә таяна. Бу исә ике телдә аралашу күнекмәләре үскән һәм баеган икетелле сөйләм тирәлеген булдырырга ярдәм итә.

Тел белән мәдәният бик тыгыз бәйләнештә яши. Шуңа күрә без, башка телне өйрәнгәндә, үзебез дә сизмәстән, шул милләтнең мәдәнияте, тарихы һәм гореф-гадәтләре белән танышабыз. Нәтиҗәдә, кешенең белем дәрәҗәсе үсә, аралашу даирәсе торган саен киңәя бара, үзенең ана теленә, мәдәниятенә башкача карый башлый, чөнки ул аларны чагыштырып карау мөмкинлегенә ия була һәм иң мөһиме — телне өйрәнү башкаларга карата сабыр булу, үзара килешеп яшәү кебек уңай сыйфатларны формалаштыра, төрле каршылыкларны кисәтә һәм халыклар дуслыгын ныгытуга ярдәм итә. Ике яки

аннан да күбрәк телләр белү кешенең һәрьяклап үсешенә дә уңай йогынты ясый, чын мәгънәсендә аның акыл дәрәҗәсен үстерә.

Әлеге хезмәттә, татар телен чит тел буларак укыту методикасының концептуаль нигезләмәләрен эшләгәндә, Россия һәм башка илләр иҗтимагый лингвистикасы, лингводидактикасы, психологиясе һәм психолингвистикасы казанышларына, алдынгы педагогик тәҗрибәгә һәм эксперименталь тикшеренү нәтиҗәләренә таяныдды.

Шуңа бәйле рәвештә татар телен укытуның лингводидактик нигезләрен төзүнең кайбер проблемаларын хәл итәргә кирәклеге ачыкланды:

✧ методика фәненең аралашу принцибын магистраль категория буларак нигезләү һәм дәлилләү. Ул исә өйрәнелә торган телне белем бирүнең башлангыч чорыннан алып аралашу өчен, табигый булган яисә аларга бик якын торган шартларда куллануны күздә тота;

✧ өйрәнелә торган телдә сөйләм эшчәнлеген тормышка ашыру ысулы буларак тәкъдим ителергә тиешле тел материалын сайлап алу һәм аны оештыруга функциональ-семантик яктан чыгып якын килү;

✧ уку процессында даими рәвештә ситуатив-тематик принциптан файдалану. Бу исә тел өйрәнүне табигый аралашуга якынайтырга ярдәм итә;

✧ укытуны сөйләм эшчәнлегенең һәрбер төренә ия булырдай итеп оештыру һ. б.

Яңача белем бирү «Башлангыч гомуми белем бирү оешмалары» (2009), «Төп гомуми белем бирү оешмалары» (2010), «Урта (тулы) гомуми белем бирү оешмалары» (2012) өчен төзелгән Федераль дәүләт стандартлары, «Мәгариф турында Россия Федерациясе Законы» (2012), «Мәгариф турында Татарстан Республикасы Законы» (2014) гомуми белем бирү оешмаларында тел фәненең дә, заман сулышын тоеп, үзгәреп торуын таләп итә. Димәк, бу очракта ике яклы икетеллелекне (милли-рус, рус-милли икетеллелеген) тормышка ашыру кирәк була. Мондый ситуациядә методикага караган кайбер проблемаларны хәл иткәндә, педагогик процесста катнашучыларның—беренче чиратта укытучыларның — эшчәнлеген активлаштыру мөһим. Укытучы күпләгән методик системалар арасыннан хәзерге шартларга ярый торганын, аерым бер телне (бу очракта татар телен) укыту процессына туры килгәнен сайлап алырга тиеш.

Шулай итеп, монографиядә телебезне укытуның теориясе һәм практикасына караган түбәндәге бурычлар яктыртыла:

✧ рус һәм башка милләт вәкилләренә татар телен өйрәтү тарихына диахроник һәм ретроспектив күзәтү ясау;

✧ татар телен чит тел буларак укыту методикасының бүгенге торышы белән таныштыру;

✧ татар телен укыту методикасының башка фәннәр белән бәйләнешен күрсәтү;

✧ методик аспектны истә тотып, татар һәм рус телләренә чагыштырма-типологик характеристика бирү;

✧ телгә өйрәтүнең лингвистик, психологик, педагогик һәм методик нигезләрен яктырту;

✧ белемнең сыйфатына уңай йогынты ясый торган педагогик технологияләр белән таныштыру;

✧ татар телен сөйләм эшчәнлеге төрләренә үзара бәйләнешле итеп укыту юлларын тәкъдим итү.

Монографиядә татар телен укыту методикасының актуаль проблемалары яктыртыла, шулай ук рус телендә гомуми белем бирү оешмаларының эш тәҗрибәсе, рус һәм чит телләр укыту методикасы, милли республикалардагы бу өлкәгә караган хезмәтләр дә искә алына, һәм ул Федераль дәүләт белем бирү стандартлары таләбенә туры килә.

# I бүлек

## ИКЕТЕЛЛЕЛЕК һӘМ КҮПТЕЛЛЕЛЕК – ЗАМАН ТАЛӘБЕ

XX гасыр ахыры—XXI гасыр башында җәмгыятьтә бара торган фәнни-техник яңарыш, геополитик ситуациянең тамырыннан үзгәрүе каршылыклар китереп чыгарды һәм аның уңай хәл ителүе телләргә, мәдәниятләргә карашны үзгәртүне дә таләп итә. Икетеллелек һәм күптеллелек мәсьәләләре алгы планга чыкты, әлеге проблеманың үз вакытында хәл ителүе милләтләр арасында тигез хокуклы мөнәсәбәтләр булдыруга, аларның тел һәм мәдәниятләренең торышына бәйләнгән.

Бу чорда Татарстан Республикасында барлыкка килгән белем бирү системасы татар һәм рус телләренең гармонияле үсеш нәтиҗәсе булып тора. Ул башка телләр өчен дә уңай җирлек тудыра торган яңа тел ситуациясен күрсәтә.

Билгеле булганча, тел—уй-фикерне белдерү, әйләнә-тирәдәге чынбарлыкны танып белү чарасы һәм, иң мөһиме, күптелле (полилингваль) җәмгыятьтә, әгәр кирәкле шартлар тудырылса, аралашу чарасы булып тора. Димәк, икетеллелек — хәзерге вакытта котылгысыз иҗтимагый күренеш. Кеше, бер сәбәпсездән яисә ихтыяҗы булмаса, икенче телдә сөйләшми, туган теле аның өчен аралашу коралы булып кала. Әмма, күпмилләтле дәүләттә яшәгәч, аңа башка телләрне үзләштерү дә кирәк була. Безнең республикада бүгенге көндә шундый хәл күзәтелә: татарларга—рус телен, русларга татар телен белү иҗтимагый ихтыяҗга әйләнеп бара. Хәзерге вакытта татар теле мәдәният, фән һәм белем бирү өлкәсендә, массакүләм мәгълүмат чараларында (пресса, радио, телевидение, Интернет), җәмгыятьтәге мөнәсәбәтләр өлкәсендә һәм көнкүрештә шактый киң кулланыла. Моннан тыш, татар телен Җир шарының дистә миллионлаган төрки телле халык вәкилләре аңлый, ягъни шул илләрдә яшәүчеләр белән халыкара бәйләнешләр оештыру мөмкинлеге туа. Шуны да ассызыклап үтәргә кирәк: гармонияле икетеллелек формалаштыру татар һәм рус телләренең дустанә яшәвен күздә тота. ЮНЕСКО мәгълүматлары буенча татар теле дөньяның тиз үзләштерелүче 14 теле исәбенә керә һәм үзенең төзеклеге, сүз формаларының тәгәлләнгәнлеге буенча дүртенче урында тора.

Дөньяда иң киң таралган телләрнең берсе—рус теленең Россия Федерациясендәге милли телләр арасында әһәмияте гаять зур.